Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Уразлы авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

15 июнь, 2020 ел № 137

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Уразлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында

2019 елның 12 ноябрендәге 367-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Уразлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2012 елның 14 сентябрендәге 49 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясындагы 3 пункты, 86 статьясындагы 5 пункты (бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмәләр әзерләү сроклары өлешендә) 2021 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булуын туктатып торырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Уразлы авылы, Тынычлык ур., 7;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кече Карамалы авылы, Кече ур., 1,

һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Уразлы авыл җирлеге
Башлыгы, Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Уразлы авыл җирлеге
Советы рәисе М.Г.Хәмидуллин